


Бvгенге яшьләребез турында кvп сойлибез һәм торле яктан бәя бирергә яратабыз. Менә мин янәшәмдә яшәп шулкадәр Ватанын яраткан киләчәк буын турында ишетеп кенә тvгел, кvнел кvзем белән кvрәм. Шундыйларнын берсе турында сvзем.

Патриот яшь буын тынычлыкны Боек Ватан сугышында нинди олы бәя биреп яулаучылар турында онытмый: батырлыклар кvрсәткәннәр белән горурланып, vзләренен балаларына сойләп тәрбиялиләр.Шулай, «ВКонтакте» сайтында Эльдар Рауф улы Долотказиннын битендә шундый сvзләргә тап булдым: «Безнен Үлемсез полк...      9 май - Россия очен әһәмиятле кон. Бу сугышта һәм анын беткәненнән сон сынган тормышларнын гигант санын, авырлыкларын һәм мәхрvм ителvләрен искә тошерv очен сәбәп. Моны истә тотарга кирәк!»
Эльдар Рауф улы язмасында кыскача бабасы Вәли Абдурахман улы Долотказин турында сойләнә. Ул текст тvбәндә.
Вәли Абдурахман улы Кадошкино районы Большие Поляны авылында колхозчы Абдрахман Салих улы белән Әминә Әбәйдулла кызы гаиләсендә 1923нче елны доньяга килә. Барлык авыл малайлары тосле, авыл тормышын тоеп, урамда бергәләп уйнап vсә ул. Мәктәптә бик яхшы билгеләренә укый. Боек Ватан сугышы башлана. 1941 елнын 23 июнендә фронтка алына. 3-нче Белоруссия фронты составында миномет исәп-хисап командиры була. Мәскәv, Тверь, Калуга, Смоленск олкәләрен азат итvдә, Ватаныбыз азатлыгы очен барган каты сугышларда катнаша. Белоруссияне азат итә. Фашистларны тар-мар итvдә зур олеш керткән Вәли Абдурахман улы ике тапкыр яралана. 1942 елнын 18 мартында беренче тапкыр кулы яралана. Ярасын дәвалап чыккач, 1943 елнын 31 октябренә кадәр дошманга каршы сугыша. Бу конне шартлаган снаряд кыйпылчыгы

беләң икенче тапкыр каты яралана. Сугыш хәрәкәтләрен дәвам итә алмау сәбәпле, запаска жибәрелә.  Дәваланып ойгә 1944 елнын июлендә, сугыш тәмамланганнан сон, 2нче торкем инвалидлыгын алып кайта. Авыр физик хезмәт беләң шогыльләнә алмаганга, башта хисапчы, аннары Кадошкино районынын «Победа» колхозынын баш бухгалтеры булып озак еллар эшли; һәрвакыт хормәттә була.
Батыр сугышчы Вәли Абдурахман улы Долотказин туган иле очен корәштә Ватан сугышы ордены, Сугышчан казанышлары очен медале, Батырлык очен медале, фашист Германиясен жингән очен медаль (орден Отечественной войны, медаль за боевые заслуги, медаль за отвагу, медаль за победу над фашистской Германией) беләң бvләкләнгән. Оч бала әтисе.
Бабаларыбыз батырлыклары очен, тынычлык очен рәхмәт йозеннән истәлек саклыйк!

**Наилә НАСЫРОВА**